ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш ); 2009, № 12 (I өлеш ); 2010, № 7 (II өлеш ); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 10, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар килеп чыгу яисә таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм биналарда лаборатор тикшерену ысуллары кулланып уздырыла торган дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны (алга таба – эпидемиягә каршы чаралар) үткәрү буенча гамәлләр башкаруны оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирелә.»;

2) 5 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 10 статьяда:

а) 1 пунктның 1 өлешендәге «эпидемиягә каршы чараларны үткәрү һәм өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүне оештыру турындагы гамәлдәге законнарның» сүзләрен «тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнарның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештәге «эпидемиягә каршы чараларны үткәрү һәм өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итүне оештыру турындагы гамәлдәге законнарны» сүзләрен «дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнарны» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 декабрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының 2 һәм 4 пунктларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасын һәм 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 10);

3) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 11 ноябрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасын һәм 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 11 (I өлеш).

**3 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2014 елның 11 ноябре
№85-ТРЗ